Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, бүген балаларга да, укытучыларга да күпкә катлаулырак. Балаларның да, аларның әти-әниләренең дә, гаиләнең мәктәпкә мөнәсәбәте дә үзгәрде. Бу гаилә әгъзаларының бер-берсе белән көннән-көн азрак вакыт үткәрүләре белән аңлатыла, телевизор һәм компьютер аралашуны алыштырды. Балаларның күбесе имин булмаган яки тулы булмаган гаиләләрдә яши. Күп кенә балалар бер-берсе белән авыррак аралаша. Укытучылар күбрәк вакыт сыйныфтагы тәртип турында кайгыртырга мәҗбүр булалар. Еш кына агрессив һәм «идарә итәргә бирелми торган» балалар белән эшләргә туры килә. Укытучы алдында уку процессын психологик яктан уңайлы итү, сыйныфта ышаныч һәм үзара ярдәм итү, бер-берсе һәм укытучы белән дустанә һәм ачык аралашу атмосферасы булдыру бурычы тора.

Бу бурычларны хәл итү өчен башлангыч мәктәптә, дәрестә һәм дәрестән соң, без К.Фопель, И.Никольская, Г. Бардиер, М. Битянова, Б. Зольцерман һәм Н. Рогалева кебек психологлар һәм педагоглар тәкъдим иткән төрле интерактив уеннарны куллана башладык.

Чөнки нәкъ менә уеннар барышында, укучыларның яңа тәэсирләр алу мөмкинлеге, социаль тәҗрибә булдыру һәм бер-берсе белән аралашу гадәти мәктәп тормышындагы кебек булмый. Ә укытучы балаларга үзенең уникальлеген аңларга, түземлерәк, игътибарлы булырга, стресслар, куркулар азрак кичерергә һәм үзләрен ялгыз хис итмәскә ярдәм итәчәк. Балаларны гади тормыш принцибына өйрәтү мөһим: ялган һәм билгесезлектән кач, эшеңне ахырга кадәр җиткер, булганның кадерен бел, башкаларга үпкәләмә, башка кешеләрнең дә синең уйларыңны укуларын көтмә. Син аларга нәрсә теләвең, хис итүең һәм уйлавың турында әйт, сиңа авыр булганда, башка кешеләргә һөҗүм итмә, гаепләмә.

Уен ярдәмендә балаларда көч һәм җитезлектән башлап креативлыкка һәм аралашучанлык кебек сыйфатлар үстерергә мөмкин. Уенда танып белүгә, аралашуга, әйләнә-тирә мохитне үзгәртеп коруга кирәк булган тормыш ихтыяҗлары булдырыла. Бала, гамәлләргә дә, эчке мотивларга да таянып, реаль һәм хыялый,уйлап табылган ситуациядә эшләргә өйрәнә. Уенда ул яңа социаль рольләрне үзләштерә, әхлакый кыйммәтләрне формалаштыра, үз һәм башка гамәлләр, кичерешләр, проблемаларның мәгънәсен аңлый. Гомумән алганда, уен — балаларны тормышка әзерләү ысулы, аларны үстерү һәм тәрбияләүнең психологик-педагогик чарасы булып тора.

Уенның күп функцияле булуын исәпкә алып, дәрестә аны куллану ысуллары:

– ял итү;

– бер эшчәнлек төреннән икенче төргә күчү;

– танып-белү процессларын (кабул итү, хәтер, фикерләү, гәүдәләндерү) үстерү ысулы;

– тирә-юньне танып белү, хәбәрдарлыкны үстерү ысулы;

– үз-үзеңне җайга салу, үзеңнең психик халәтләреңhәм гамәлләреңбелән идарә итү күнекмәләрен үстерү ысулы;

– иҗади сәләтләрне үстерү ысулы һәм индивидуальлек чагылышы (оригинальлек, үзенчәлеклелек, стандарт булмаганлык);

– бала өчен мөһим булган вакыйгаларны, кичерешләрне, уй-фикерләрне эмоциональ белдерү ысулы;

– психологик киеренкелекне бетерү ысулы;

– социаль күнекмәләрне үстерү ысулын формалаштыру;

Дәресләрдә һәм дәрестән тыш эшчәнлектә кулланыла торган уеннар.

Утын кисү

Максатлары: бу уен озак утырып башкарыла торган эштән сон актив эшчәнлеккә күчәргә ярдәм итә. Балалар үзләренең тупланган агрессив энергияләрен тоя һәм аны уенда куллана алачаклар. Моннан тыш, уен вакытында кычкыру эмоциональ бушануга булыша һәм сулышны яхшыртырга ярдәм итәчәк.

Инструкция. Кайсыгызның утын ярганы яки карап торганы бар? Бу ничек эшләнә? Кем күрсәтә ала? Утын кискәндә балтаны ничек тотарга кирәк, аяклар нинди хәлдә булырга тиеш?

Бераз буш урыннар калдырып шулай басыгыз. Күз алдыгызга китерегез, сезгә берничә утын ярырга кирәк. Миңа, ярасы бурәнәнең юанлыгын курсәтегез. Аны агач төбенә куегыз һәм балтаны баш өстенә күтәрегез. Һәрвакыт балтаны төшергәндә каты иттереп «Ха!. дип кычкырырга кирәк. Аннары икенче шакмакны куегыз һәм янәдән ярыгыз. Ике минуттан соң һәрберегез күпме шакмак ярганын әйтерсез.

Җилпенү

Максатлар: тормыш юлында уңышка ирешүнең иң катлаулы каршылыкларының берсе-безнең уңышсызлык һәм җиңелүләр турындагы истәлекләр. Бу уен барышында балалар барлык тискәрелекне, кирәк булмаган һәм комачаулый торганны жилпенеп төшергәнне күз алдына китерәләр.

Инструкция: арыганлыктан, күңелсез хисләрдән ничек җиңел котылу мөмкинлеген күрсәту.

Мөгаен, сезнең һәркайсыгызның юешләнгән этнең ничек жилпенеп кибенгәнен күргәнегез бардыр. Ул аркасын һәм башын шулкадәр көчле итеп селкетә, бөтен су читкә очып китә. Сез якынча шул ук эшне башкара аласыз. Үзегезгә җитәрлек урын калдырып түгәрәккә басыгыз, учларны, терсәкләрне, җилкәне селкетә башлагыз. Шул ук вакытта күз алдыгызга китерегез әле, ничек барлык күңелсезлекләр, эттән су очкан кебек, сезнен остән очып китә. Соңрак аякларыгызны селкетегез. Ә аннары башны селкетегез. Шул ук вакытта нинди дә булса тавышлар чыгара аласыз. Хәзер битне селкетегез һәм авызны селкеткәндә тавыш ничек кызык үзгәргәнен тыңлагыз. Күз алдыгызга китерегез, бөтен күңелсез йөк сездән китә, һәм сез

барыгыз да шат һәм көр булып каласыз. (Әлеге күнегү өчен 30–60 секунд вакыт бирелә).

Психологик уеннар

Кар бөртекләре. Күнегүләр музыка ярдәмендә башкарыла.

Укытучы: «Карагыз әле, күктән нәрсәдер төшә. Сул кулны сузыгыз, кулларыгызны ачыгыз. Уң кулыгызны сузыгыз, учыгызны ачыгыз. Кулларыгыз белән кар бөртекләре тотыгыз. Өскә таба сузылыгыз. Тирән сулагыз. Кулларыгызны аска төшерегез, кулдан кар бөртекләрен кагыгыз. Сулагыз. Тагын бер кат кабатлыйбыз» «.

Шарны кабартабыз. Төркемдәге һәр катнашучыга шарлар өләшегез.

«Үз шарларыгызны кабарта башлагыз...» Беренче баланың шары бик нык кабаргач яки шартлагач: «Менә, балалар, күрегез сезнең хисләр белән дә шулай була. Әгәр дә син үзеңдә ачуны озак саклыйсың икән, ул үсә, үсә һәм шартлый. Шарны ныграк кабартыгыз әле һәм тотып карагыз, аның тыгызлыгын һәм көчен сизәрсез, шарнын эчендәге тынны чыгармыйча тоту бик авыр. Эчтәге ачу белән дә шулай ук. Ә хәзер әзрәк кенә һаваны чыгарып карагыз. Ул бераз йомшаграк, әмма инде аның белән уйнап була, ул инде шартламаячак. Алып баручы: Балалар, сезнең ачуыгыз килгәндә, шарыгыз ни дәрәҗәдә кабара? Сөйләп карагыз әле. Ә хәзер шар белән эшләп күрсәтегез. Шарны сез теләгәнчә кабартыгыз.

Сулыш ярдәмендә тынычлану. Әгәр дә безнең бик каты ачуыбыз килә икән, безнең сулыш ешая һәм һава тиешле күләмдә организмга килеп җитә алмый. Без шушы халәттә озак итеп игътибар итмичә торсак,

дөрес суламаганлыктан «Хәзер мин шартлыйм» дигән хис туарга мөмкин. Шуңа күрә, ачуны җиңү өчен, тизрәк сулышны дөрес алырга өйрәнү бик мөһим. 5 тапкыр тирән итеп сулыш аласың һәм әкрен генә ул сулышны чыгарасың, һава агымының ничек итеп үпкәләргә тулганын һәм аннан чыкканын сиземләргә кирәк. Шушы үпкәдән чыккан һава агымы белән бездән ачу да чыгып бетә, кеше тынычлана. Талгын гына агылган көй дә шулай ук тынычланырга ярдәм итә.

Үз-үзеңне кулга ал. Борчылуыңны сизүгә, кемнедер тукмыйсы, нәрсәдер атасы килсә, үз көчеңне исбатлау өчен бик гади ысул бар: терсәкне тотып, кулыңны күкрәккә нык итеп кыс, — бу түземле кешенең торышы.

Үпкәсез, талашсыз, уйный, укый, эшли алганда күңелдә җылы һәм рәхәт була, һәр нәрсә белән шөгыльләнү кызыклы һәм кызыктыргыч була.

Ә кешеләр бер-берсен аңларга һәм авыр минутларда ярдәм итәргә тырышканда, дуслык туа. Әгәр дуслар арасында аңлашылмаучанлык килеп чыкса, алар бәхәснең сәбәбен аңларга тырышсалар һәм бер-берсенә юл куя алсалар, ул һичшиксез хәл ителәчәк.

Татарча «дуслаштыру санамышлары». Кем белә аларны күбрәк?

Балалар куп вакыт үзара талашалар, конфликтларга керәләр, шул вакытта иң үтемле ысулларның берсе булып дуслаштыру санамышлары тора. Шушы санамышлар ярдәмендә балалар тизрәк дуслашалар, уртак тел табалар, упкәләрен оныталар, бер-берсенә карап елмаялар. Мисал очен: балалар арасында конфликт килеп чыкса аларны бер-берсе каршысына бастырып, элеге өйрәнгән санамышны

әйтәләр: «Дус бул, дус бул, бүтән сугышма! Дуслашу мәңгегә! Бүтән талашма!»

«Без синең белән бертөрле» коллективны берләштерү уены.

Уенчыларның бурычы: сыйныфташлары белән охшашлыкны табу һәм әлеге охшашлык нигезендә укучыны түгәрәккә чакыру, кабатланырга ярамый.

Мәсәлән: «Әлфия, без синең белән бер йортта яшибез»,» Алмаз, без синең белән бер буйда».

Уен барлык укучылар да түгәрәккә чыгып беткәнче дәвам итә.

Уенының азагы «Без барыбыз да охшаш, бергә — без көч» дип тәмамлана.

Мондый дәресләр һәм интерактив уеннар үткәрү безгә күп максатларга ирешергә ярдәм итә:

1. Иптәшләреңә белән бердәмлекне тою.

2. Балаларга өмет, ышаныч тудыру. Балалар җиңүнең тәмен татырга һәм җиңелүләрне дөрес итеп үткәреп җибәрергә өйрәнәләр. Ул балаларга һәм өлкәннәргә көч һәм куйган максатка ирешү юлын күрсәтә. Балаларга авыр хәлләрне кичерергә һәм киләчәккә ышаныч белән карарга ярдәм итә.

3. Балаларга үз сүзен әйтергә һәм башкаларга карата үз карашын белдерергә, кыюлыгын үстерергә булышу. Чөнки үрнәк алырлык кешеләр белән мөнәсәбәтләрне бозудан куркып, балалар еш кына үзләрен өлкәннәр кебек тоталар, дәшми торалар, аларга күңелсез, үз теләкләрен белдермичә башкалар фикеренә кушылалар, үз карашларын белдермиләр.

4. Балаларга үз куркуларын ничек җиңәргә өйрәтү, бер-береңне рәнҗетмичә дә яхшы яшәп булганын аңлату.

5. Балаларны үз ачуларын контрольдә тотарга һәм тулган агрессияне уен формасында чыгарырга өйрәтү.

6. Балаларның характерының көчле якларын үстерү. Аларны яратырга, кайгырырга, кешеләрне хөрмәт итәргә, түземлелеккә өйрәтү

Кулланылган әдәбият:

1. Фопель К. Как научить детей сотрудничать? Психологические игры и упражнения: практическое пособие / Пер. с нем.; В 4-х томах.

2. Интернет материаллары.

Ихсанов Василь Бурганович,
учитель обществознания
МБОУ «Сармановская гимназия»

МАТЕРИАЛЫ УФИМСКОГО ЗЕМСТВА ЗА 1870–1912 ГОДЫ КАК ИСТОРИЧЕСКИЙ ИСТОЧНИК НА УРОКАХ

Использование местного, краеведческого материала оживляет уроки, вызывает заинтересованность у учащихся. Подобные материалы и сведения можно применять не только на уроках истории и обществоведении, но и на других уроках социально-гуманитарного цикла.

В последние десятилетия архивы, центральные публичные и научные библиотеки начали оцифровывать свои архивные фонды, также имеющиеся у них старинные книги, редкие издания, газеты и журналы давно прошедших времен. Начали их размещать в интернете в открытом доступе для широкой публики. Эти материалы представляют большие возможности для изучения, как для любителей истории, так и для других учителей. Применение местного материала чрезвычайно актуально при изучении истории Татарстана. Это объясняется хотя бы тем фактом, что часть восточных районов Татарстана относилась к Уфимской и Оренбургской губерниям, а северо-восточные районы к Вятской губернии. История этих районов до 1920 года, года образования ТАССР, практически не упоминается.

Этот информационный пробел нам помогают заполнить публикации Государственной публичной исторической библиотеки статистической отчетности

губернского земства под названием «Обзор Уфимской губернии» за 1870–1912 годы, всего сорок два тома материалов. Материалы за 1913–1917 годы не представлены, что можно объяснить начавшейся мировой войной и революциями 1917 года,

Уфимское губернское земство формально начало работать в 1864 году. Лишь в 1870 году оно начало работать и выполнять полноценно свои функции. Мензелинский уезд являлся одним из пяти уездов этой губернии. Мензелинское уездное земство тоже составляло свои отчеты о проделанной работе, но они не были опубликованы, по этой причине мы обращаемся к опубликованным материалам уфимского губернского земства.

Из этих 42-х томов первые восемь томов написаны от руки каллиграфическим почерком. Тома, выпущенные в последующие годы, как правило, изданы типографским шрифтом.

Содержание каждого тома характеризуется подробным и серьезным описанием состояния положения дел в губернии.

В каждом томе сначала дается анализ земледелию, обеспечению народного продовольствия, состоянию промышленности заводской и фабричной, торговле, промыслам населения и перемещения населения. Уделяется большое внимание погодным условиям, количеству осадков, уровню снежного покрова и прохождению паводков, так как от состояния природно-климатических условий зависело зерновое хозяйство и скотоводство края, от которого зависела вся жизнь населения губернии.

Следующая глава отчета называется «Общественное благоустройство и благочиние». Где речь идет об общественных зданиях (больницы, тюрьмы, здания

земских учреждений, училища, школы и т. д.). Там же речь идет о строительстве дорог, мостов и переправ. Уделяется много внимания общественной нравственности, содержанию арестантов, их обеспечению продовольствием, постельными принадлежностями и занятиям. Арестантов пытались приучить к труду и грамоте. Подробно описываются крупные пожары с указанием деревень и уездов. Указываются причины пожаров. Очень подробно рассматривается положение дел с раскольниками. Католики, лютеране и иудеи находятся под особым вниманием. Работа почты всегда находится под контролем, оценивается состояние почтовых трактов и обеспеченность лошадьми.

«Народное здравие и общественное призрение» — глава отчета посвящается положению дел с больницами, фельдшерскими участками и аптеками, также оспопрививанию населения. Называются виды болезни у домашнего скота, причины этого и принятые меры. В этой же главе подробно дается анализ всем преступлениям, классификация которых представлена по сословиям, разделению на городское и сельское население, конфессиональной принадлежности и видам занятий. Также анализируется положение богаделен.

Интерес представляет описание различного типа учебных заведений губернии. Земство пыталась их обеспечить необходимым помещением, дровами, учебными пособиями, учителями и зарплатой. Можно сказать, что проблемы в те времена были схожи по содержанию, с современными.

Погодные условия и полученный урожай, цены на продовольственные товары, зарплаты разных сословий были в центре анализа земства и уездной власти. В конце 19 века поименно начинают упоминать

пароходы и их роль в хозяйственной жизни губернии. А в начале 20 века большое внимание уже уделяется железнодорожным перевозкам, дороговизне и недостаточной эффективности гужевого транспорта.

Содержание публикаций и их объем меняется к началу двадцатого столетия: дается отчетность по банковским делам, подписке на периодическую печать, качественные показатели рекрутов, применение новых технологии в земледелии. С конца 19 века ведется отчетность о состоянии пришкольных опытных участков, отмечается стремление учителей детей приучить к садоводству и огородничеству. В мензелинском уезде садоводством и огородничеством занимались только русские жители, и то живущие близко к городам. В то же время делались попытки приучить крестьян к промыслам, целью этого являлось выведение хотя бы части населения из состояния нищеты. Помещики и православное духовенство имели пасеки, сады и огороды, что подробно описывается и в других источниках.

В конце 19 века в губернии увеличилось количество спиртзаводов. Они, с одной стороны, давали работу части населения края. Принимали зерно местного населения на переработку, обеспечивали местное население бардой для корма скоту. В то же самое время в населенных пунктах открывались трактиры и прочие питейные заведения. Они обеспечивали поступление налогов в местную казну. Общественность создавала общества трезвости, православное и мусульманское духовенство выступали против спаивания населения. В этом вопросе мы наблюдаем наличие противоположных интересов различных слоев общества и правительства.

Отдельные публикации посвящаются натуральным повинностям населения, таким как подводная,

гужевая и постойная. Подводная повинность состояла и том, чтобы крестьяне на своей подводе должны были перевозить чиновников, в редком случае проходящие войска обычно на 30 верст. Гужевая повинность включала в себя перевозку казенных грузов. Постойная повинность означала дать кров проезжающим гражданам по казенным надобностям при отсутствии постоялого двора в населенном пункте. Если с начала эти повинности выполнялись бесплатно, то с конца 19 века земство начало оплачивать эти повинности. Повинности эти выполнялись жителями по очереди и тогда считалось их выполнение обычным и обязательным делом.

Первые телефоны в губернском городе Уфе появились в 1897 году. В 1908 году телефонные линии в губернии имели протяженность в 563 версты. Имелось 357 переговорных пунктов для публики. В 1908 году было сделано 662 918 звонков, что на 166 378 больше, чем в 1907 году. Мензелинское земство и местное купечество шли в ногу с техническим прогрессом. Тем более мензелинская ярмарка приносила большие налоги в казну земства, да и телефонизация края сулила увеличение прибыли местным предпринимателям. В 1912 году мензелинское земство решило провести телефонную линию из Мензелинска в Набережные Челны, дальше соединить их с волостными центрами Большое Нуркеево, Карамалы-Александровка и в город Бугульму. Нуркеево планировали соединить с волостным центром селом Языково и дальше протянуть линию до пригорода Заинска. Для осуществления технической стороны проекта обратились к инженеру, одного из братьев известных купцов Стахеевых. Первоначально он запросил большую плату за работу, но претворив в жизнь этот проект, отказался от платы за свою работу в

пользу мензелинского земства. Эта сумма равнялась 25 тысячам рублей, громадные деньги в те времена. Таким образом, в 1913 году значительная часть мензелинского уезда могла пользоваться телефоном. Цена за пользование телефоном была весьма чувствительная и не все могли им воспользоваться.

Рассмотрим несколько примеров использования материалов земств на уроках. Распространено мнение, что раньше рождалось в семьях много детей. Если взять данные по некоторым деревням Мензелинского уезда Уфимской губернии, то число родившихся детей значительное. Посмотрим положение дел в нескольких населенных пунктах, откуда в Сармановскую гимназию возили учащихся с 1 по 11 классы, общее количество учащихся из каждой деревни умещаются в 20-местный автобус. В 1883 году в деревне Дими Тарлау родились 36 детей, в Рангазаре 48 детей, в Новом Ахметево 22 ребенка. Детская смертность в конце 19 века была высокая, более 60% умирали до 5 лет, еще 10–14% умирали от разных причин до 15 лет. Обеспеченность врачами и аптеками, лекарствами была очень низкой.

Приведем пример использования отчетов земств на уроке обществознания в 11 классе. При прохождении темы «Источники права» все учебники, в том числе вузовские в пример правового обычая приводят долговую расписку в простой письменной форме на клочке бумаги. До революций 1917 приговор сельского схода являлся примером правового обычая (Приложение 1). Примером правового обычая даже в наше время является порядок выпаса скота в сельской местности. Выселение из населенного пункта кого-то «за дурное

поведение» теперь обычно не практикуется, хотя примеры имеются.

Материалы земств можно применять как примеры на уроках, проведении бесед с учащимися и исторических исследованиях.

Изучение прошлого и настоящего родного края позволяет ввести учащихся в сложный и противоречивый мир общественных отношений и помогает им научиться жить в этом мире, способствует выработке собственной жизненной позиции. Краеведение способствует формированию у учащихся представления о себе как гражданине общества. При этом учитывается единство научного, дидактического, методического и воспитательного начал. Важно, чтобы ребёнок погрузился не только в мир представлений о прошлых эпохах, но и связал их с системой ценностей своего мира.

Краеведческая деятельность позволяет выстраивать новые, объектно-субъектные отношения учителя и ребёнка. Поисковая, исследовательская работа — это всегда сотворчество педагога и ученика.

Кроме того, в процессе краеведческой работы у детей формируется чувство любви к Родине, родному краю; уважение к своему и другим народам, складывается миропонимание. Развиваются память, внимание, наблюдательность, расширяется кругозор и словарный запас. Развиваются коммуникативные качества личности. При этом надо помнить, что если получилось зародить в ученике интерес к истории родного края, его следует постоянно поддерживать, помогать ребенку в преодолении трудных ступенек, ведущих к знаниям.

Литература

1. Мухаметшин З. Метрикә дәфтәрләре — хәтер сагында // Мирас. 2013. №5.

2. Митрофанов Т.С. Волостные суды Казанской губернии: правосознание, закон и обычай // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2019. №1.
3. История башкирских родов / под ред. Ф.Х. Гариповой. Уфа: Китап, 2016.
4. Салахова Э.К. Мусульмансике метрические книги России // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2018. № 1.
5. Татары уфимского уезда (материалы переписей населения 1795–1859 гг.) — Справочное издание. Казань. 2022.

Матзянова Раушания Гаяз кызы,
Хәйруллина Эльза Илдар кызы,
МБГББУ «Сарман гимназиясе» укытучылары

ТАТАР ҺӘМ РУС ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ПРОЕКТ ЭШЕНЕҢ БАШКАРЫЛУ ЮЛЛАРЫ

Тел дәресләрендә, шулай ук фән буенча дәрестән тыш эшләрдә проект эзләнү эше актуаль.

Проект — әле булмаган нәрсәне барлыкка китерүгә юнәлтелгән һәм аның тормышка ашу процессын күзаллаган идея. Шуның өчен дә проект алдына куелган максат төзү, барлыкка китерү, булдыру, иҗат итү, ирешү һ.б. кебек өлешләрдән тора.

«Проект» — фарсы теленнән алга атлаучы, алдан баручы дигәнне аңлата. Проект методын куллану ул алган белем һәм күнекмәләрне системалаштыру, мөстәкыйль эшчәнлек, фәннәр арасында бәйләнеш табу, кызыксындырган проблеманы билгеләү, чишү юлларын табу, көтелгән нәтиҗәне билгеләү.

Без дәресләрдә һәм дәрестән тыш эшләрдә укучылар белән проектлар эшлибез, өстәмә информация туплыйбыз һәм системалаштырабыз. Проект эше укучы өчен иҗади мөмкинлекләрен ачарга, төркемдә эшләү күнекмәләрен булдырырга, үзләре өчен кызыклы проблемаларны ачу өстендә эшләү тәҗрибәләре булдырырга һәм аудитория алдында чыгыш ясап, эзләнү эшләрен тәкъдир итәргә ярдәм итә.

Туган якка, аның тарихына, күренекле кешеләренә багышланып эшләнелгән проектлар бүгенге көндә мәктәптә патриотик тәрбиянең бер юнәлеше булып тора. Шунлыктан укучыларыбызга Сарман

тарихы, якташ язучыларыбызга багышланган проект темалары тәкъдим итеп, кече Ватанга мәхәббәт һәм хөрмәт тәрбияләүне максат итеп куябыз. Укучыларны кызыксындырган мәгълуматлар арасында М.Рәмзине алга таба аның әнисе ягыннан абзасы, танылган мулла Исмәгыйль әл-Кашкарыйның атаклы шәкертләренең берсе, Әлмәт имамы һәм мәдрәсә мөгаллиме шәех мулла Хөснетдин тәрбияләвен, аңа ул саллы фикерләр тулы гарәп, фарсы китапларының сәхифәләрен ачуын ишетергә була.Габдулла Тукай Морад Рәмзинең Казанда акча җыеп йөрүенең чын мәгънәсен соңрак аңлый. Ул 1911 нче елда яңа «Яшен ташлары» исемле җыентыгында Морад Рәмзигә багышланган юлларны төшереп калдыра.

М. Рәмзи Петербург китапханәләрендә һәм архивларында эшләгән. «Тәлфик әл әхбәр...» әсәрендә М.Рәмзи, Ш. Мәрҗанидән соң беренче буларак, борынгы вакытлардан алып үзе яшәгән чорга кадәрге татар халкы тарихын язарга омтыла. 1914 нче елның язында ул гаиләсе белән кыска гына вакытка Россиягә кайта. Февраль революциясеннән соң М.Рәмзи Оренбург делегаты сыйфатында, 1917 нче елның июлендә Казанда узган Бөтенроссия мөселман руханилары съездында катнаша.

Укучылар төрле архивларда, иске язмаларда, чыганакларда Мөхәммәдморад Рәмзи, Мөхәммәдморад әл-Минзәләви, Мөхәммәдморад әл-Мәкки, Мөхәммәдморад әл-Мәдинәи, Тутый, Гандәлиб, Әбелхәсән, Акмал, М.М.Р.Шәех Мөхәммәд, Морад Казанлы, Морад әфәнде, Бәдәлче Морад, Шәех Морад, Морадшаһ Баһадиршанов һәм тыйнак кына язылган Морад дигән тәхәллүсләр исемнендә йөргәнлеген белделәр.

Ә хәзер эш алымының бер юнәлеше булган шәҗәрәбездәге кайбер статистикага тукталып китәбез. Безнең шәҗәрәдә барлыгы 116 гаиләдәге 502 кеше күрсәтелгән. Шуларның 56% ир-атлар, 44% хатын-кызлар. Бүгенге көндә исәннәре — 259, үлгәннәре — 243. Нәсел шәҗәрәсендәге кешеләрнең 413 өйләнгән, 89 буйдак, 11 ялгыз калган һәм бары тик өчесе генә аерылышкан.

Без барлыгы егерме бер фамилия вәкилләре барлыгын белдем. Шулар арасында иң киң таралганы — Салихов фамилиясе. Ир-ат исемнәреннән иң киң таралган исем Илнур булса, хатын-кызларда — Айгөл.

Нәселебездәге кешеләр барлыгы 5 илдә гомер кичерәләр. Күбесе Россиядә яшәсә, икесе Германиянең Франкфурт на Майне шәһәрендә, өчесе Американың Минниаполс шәһәрендә, икесе Австралиянең Сидней шәһәрендә, Швейцариянең Цюрих шәһәрендә бер туганыбыз тора.

Нәселебездәге гаиләләрдә ир белән хатын арасында иң зур яшь аермасы — 6. Гаиләдәге балалар санын уртача алсак — 3,8; иң күп бала — 9. Бала туу моментына иң өлкән яшьтәге кеше — 39, иң яше — 17. Зур һәм кече бала арасындагы иң зур аерма 12 ел, иң кечкенә аерма — 4 ел. Уртача балалар арасындагы яшь аермасы — 7,8.

Кеше тирә-якны танып белергә гаиләдә өйрәнә, аннан олы дөньяга юл ала. «Оясында ни күрсә, очканында шул булыр» дигән халык мәкале дә шуннан килеп чыккандыр, мөгаен. Әгәр бәхетле картлык күрәсегез килсә, акыллы, тәрбияле балалар үстерегез», — дигән күренекле педагог В.Сухомлинский. «Илен белмәгән — игелексез, нәселен белмәгән — нәселсез», дип, юкка гына әйтмәгән халкым. Белеп әйкән. Һәр

кешегә үзенең җиде буын бабасын белү фарыз, дигәннәр борынгылар. «Нәсел-нәсәбегезне белегез, кардәшләрегезне барлагыз, чөнки бергә яшәсәгез дә, өзелгән туганлыкта якынлык юк, ераста торсагыз да йөрешкән туганлыкта ераклык юк», диелә Мөхәммәт пәйгамбәрнең бер хәдисендә дә.

Әйе, вакыт йөгерә. Яңа буыннар җиргә килә тора. Һәр кеше үз гомерендә барысына да өлгерергә, иң мөһиме — үзе турында киләчәк буынга якты истәлек калдырырга тиеш. Әгәр дә бабаларыбызны онытсак, безне дә онытырлар. Нәсел җебебез өзелмәсен, керләнмәсен дисәк, начар эшләрдән сакланырга; үзебезнең нәсел агачыбызга зыян салмыйча, нәселебез данына тап төшермичә яшәргә кирәк.

Кулланылган әдәбият

1. Артамонова О.А. Проектные технологии в образовательном процессе.
2. Архипова Н.В. Проектная деятельность как одна из форм вовлечения учащихся в процесс исследования.
3. Бродовская З.В. Организация проектной деятельности в системе работы.

Нәҗметдинова Чулпан Мөнир кызы,
МБГББУ «Сарман гимназиясе» нең
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ПРОЕКТ ЭШЧӘНЛЕГЕН КУЛЛАНУ

Җәмгыять үсеше белән бергә, уку-укыту, тәрбия системасы да бик еш үзгәртеп корыла. Шул заман белән бергә иярeп бару өчен, укучылар белән бер дулкында булу өчен, укытучы һәрвакыт яңа метод-алымнар эзләнүдә, аларны эшендә кулланырга тиеш. Бүгенге көндә белем бирү өлкәсендә киң колач алган — проект эшчәнлеге шундый алымнарның берсе. Әлеге алым, уку-укыту эшчәнлеген кызыклы һәм файдалы итү өчен отышлы. Проект методын кулланып укыту, белем бирү процессын яңарту — үзгәртү алымнары файдаланып гамәлгә ашырырга мөмкинлек тудыра. Проектлар методын кулланып эшләү укытучыдан үз эшенә иҗади якын килүне таләп итә. Ул инде укытучы буларак кына түгел, режиссер нинди дә булса эшкә җитәкчелек итә, консультант яки башка рольгә кереп, укыту процессын оештыра.

Укучыларның танып белү мөмкинлекләрен, акыл эшчәнлеге мөстәкыйльлеген үстерүдә проектлар методы зур урын алып тора. Урта сыйныф укучылары белән эшләгәндә, төркемнәрдә эшләү һәм аерым проект эшләре башкаруны кулланырга була.

Быелгы уку елында, 5 нче сыйныф укучылары белән ике проект эшчәнлеге планлаштырылды. Беренче яртыъеллыкта, әлеге эшне аңлап башкару өчен аерым укучылар белән эш башкарылды. Проект

ике этапка бүленде. Беренче этап: укытучы белән эшчәнлек, ягъни укучыларга теманы ачыкларга ярдәм итү, план төзү, әдәбият исемлеге белән таныштыру. Икенче этапта укучы эзләнү, дөрес мәгълүмат табу һәм аларны берләштерү эшен башкарды. Туган ягыбыз һәм андагы шәхесләрне өйрәнү, аларның эшчәнлеген барлау — укучылар өчен, хәзерге буын өчен бик файдалы. Шуңа күрә дә, әлеге проект эшчәнлеге «Сарман районының танылган шәхесләре» дигән исем астында узды. Иң сөендергәне, 5 сыйныф укучыларының күпчелеге, якташ язучылар иҗатын тикшерүгә алынганнар иде. Сарман язучыларының иҗатын һәм тормыш юлын барлап, алар белән истәлекле хатирәләр, гаилә архивыннан алынган фотосурәтләр дә әзерләгәннәр.

Икенче яртыъеллыкта планлаштырылган проект эшчәнлеге бераз катлауландырылды. Беренчесендә һәр укучы үзе эшләгән булса, әлеге проект төркемнәргә бүлеп бирелде. Проектның үтәлү срогы да, эчтәлеге дә зурайтылды. Тик укучылар куркып калмадылар, бик теләп бу эшкә тотындылар. Төркемнәрдә эшләүнең уңай яклары күп булган кебек, тискәре яклары да бар. Укучыларда җаваплылык хисе югалырга мөмкин. Эшне җиңеләйтү өчен һәр төркемгә җаваплы кеше, редактор, әдәбият исемлеге, фотосурәтләр һ.б. шундый эшләр өчен җаваплы кешеләр бүленеп куелды. Төркемнәрдә эшләү, коммуникатив гамәлләрне куллануның бер төре. Укучылар аралашалар, бер-берсенең сүзләренә, уй-фикерләренә колак салырга өйрәнәләр.

Укучы өчен проект эшчәнлеге нәрсә бирә соң? Проект эшчәнлеге, сайлап алынган теманы ачыклаудан, аның эчтәлегеннән тыш, укучыларга

иҗади мөмкинлекләрен ачарга, төркемнәрдә эшләү күнекмәләре булдырырга, үзе алынган кызыклы проблеманы (теманы) ачу өстендә эшләргә, үзенең эшен (хезмәтен) презентацияләү мөмкинлекләрен бирә.

Гомумән алганда, белем бирүдә проектлар методын куллану — укучыларның иҗади сәләтен устерүгә зур этәргеч булып тора. Укучыларда яңа проектлар эшләү теләге туа һәм фәнгә карата кызыксыну уяна. Иҗади эшчәнлек тәҗрибәсенә ия булган саен укучыларның белем сыйфаты да үсә. Ә татар әдәбиятында иҗади эшчәнлек өстендә эшләү, сөйләм телен үстерү, мәгълүмат таба белү һәм аны дөрес итеп кулланырга өйрәтү безнең төп бурычыбыз.

Кулланылган әдәбият

1. Сергеев И.С. Как организовать проектную деятельность учащихся/ Уку-укыту процессында проект эшчәнлеген оештыру: Практическое пособие для работников образовательных учреждений. — М.: АРКТИ, 2003.

2. Савенков А.И. Содержание и организация исследовательского обучения школьников/ Укучылар эшчәнлегендә фәнни-тикшерү эшләрен оештыру. — М.: «Сентябрь», 2003.

Нуртдинова Раушания Равил кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы, ***Калимуллина Әлфия Нәҗиб кызы,***
китапханәчесе МБББУ «А.Тимергалин исемендәге Иске Минзәләбаш төп гомуми белем бирү мәктәбенең

МӘДИНӘ МАЛИКОВАНЫҢ «ЧӘЧКӘ БАЛЫ» ПОВЕСТЫНДА ТЕМА, ИДЕЯЛӘР ДӨНЬЯСЫ, ПСИХОЛОГИЗМ БИРЕЛЕШЕ: ТРАДИЦИЯЛӘР ҺӘМ ЯҢАЧАЛЫК (ПРОЕКТ)

Проблеманың куелышы: укучыларга М. Маликованың «Чәчкә балы» повесте аша әхлакый мәсьәләләрне, гомумкешелек кыйммәтләрен, кеше һәм җәмгыять арасындагы катлаулы бәйләнешләрне җиткерү, әсәрдәге традицияләрне һәм яңачалыкны билгеләү.

Проектның максаты: М. Маликованың «Чәчкә балы» повестенда җиткерергә теләгән төп фикерне һәм төшенчәләрне ачыклауны, психологизм бирелешен тикшереп, китап укучылар конференциясе үткәрү.

Бурычлары: повестьтагы вакыйгалар эзлеклелеген, гомуми барыш һәм хәрәкәт схемасын тикшерү, конфликтны билгеләү; әсәр нигезенә салынган вакыйгаларны, кешеләр арасындагы һәм кеше белән җәмгыять арасындагы мөнәсәбәтләрне тикшереп, «Чәчкә балы» повестеның тематикасын ачыклау, тема һәм проблемаларның идеяләр дөньясындагы чагылышын күзәтү; повестьта образның рухи дөньясын, ягъни психологиясен нинди үзенчәлекле чаралар, алымнар ярдәмендә сурәтләнүен анализлау; тема, идеяләр һәм психологизм төшенчәләрен традицияләрне

дәвам итү һәм яңачалык җирлегендә тикшерү, нәтиҗә ясау; әдәби әсәрне тикшерү нәтиҗәләре буенча, китап укучылар конференциясе уздыру.

Проектның максатчан группасы: 8–9 нчы сыйныф укучылары.

Катнашучылар: татар теле һәм әдәбияты укытучылары, китапханәчеләр.

Реализация вакыты, урыны: 2022/23 нче уку елы; Сарман районы «А.Тимергалин исемендәге төп гомуми белем бирү мәктәбе».

Тормышка ашыру этаплары

1. Әзерлек этабы.
2. Төп этап.
3. Йомгаклау этабы.

Проектны тормышка ашыру этаплары

№	Эш төре	Үткәрү урыны	Үткәрү вакыты	Җаваплы кеше
Әзерлек этабы				
1.	Тема буенча материал туплау	мәктәп	сентябрьнең беренче атнасы	татар теле һәм әдәбияты укытучылары, китапханәчеләр
2.	Чыганаклар белән эшләү	мәктәп	сентябрьнең икенче атнасы	татар теле һәм әдәбияты укытучылары, китапханәчеләр
3.	Укучылар өчен консультацияләр үткәрү	мәктәп	сентябрь - февраль	татар теле һәм әдәбияты укытучылары, китапханәчеләр
4.	План төзү	мәктәп	сентябрьнең беренче атнасы	татар теле һәм әдәбияты укытучылары, китапханәчеләр
Төп этап				

5.	Фәнни хезмәтләрне уку, анализлау	Мөстәкыйль рәвештә	сентябрь - октябрь	8-9 сыйныф укучылары
6.	Тиешле урыннарны билгеләп бару, аларны язып алу	Мөстәкыйль рәвештә	ноябрь - декабрь	8-9 сыйныф укучылары
7.	Нәтиҗәләр чыгару	Мөстәкыйль рәвештә	гыйнвар	8-9 сыйныф укучылары
8.	Чыгыш әзерләү, презентация ясау, рәсем, плакатлар конкурсы оештыру	Укытучы белән берлектә	февраль	Укытучы, 8-9 сыйныф укучылары
9.	Укучылар өчен китап укучылар конференциясе үткәрү	Мәктәпнең актлар залы	февраль	Укытучы, 8-9 сыйныф укучылары, китапханәчеләр
Йомгаклау этабы				
10.	Мәкалә язып, «Сарман» газетасында бастыру		февраль	

Проектны ресурс яктан тәэмин итү

Шартлар	
Норматив-хокукый: 1. Телләр турындагы закон. 2. Мәгариф турында закон. 3. Әдәбиятны укыту методикасы	Материаль-техник: 1. Компьютер. 2. Ноутбук. 3. Проектор.

Кадрлар: татар теле һәм әдәбияты укытучылары, китапханәчеләр.

Фәнни-методик яктан:

1. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. — Казан: Мәгариф, 2007.
2. Заһидуллина, Д.Ф., Әдәби әсәргә анализ ясау/ Д.Ф. Заһидуллина, М.И.Ибраһимов. — Казан, Мәгариф, 2005.
3. Заһидуллина Д.Ф., Татар әдәбияты:Теория.Тарих/ Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов, Т.Ш. Гыйләҗев. — Казан: Мәгариф, 2004.

Информацияләү: интернет челтәре, татар газета-журналлары.

Мотивацияләү: укучыларда китап укуга кызыксыну уяту, татар әдәбиятын тирәнрәк үзләштерү, әсәр үрнәгендә гаилә кору серләрен ачу.

Оештыру: әдәби әсәр, презентация, программа, редакция белән килешү.

Финанслау: мәкалә чыгару өчен матди ярдәм күрсәтү.

Проектның эффективлык индикаторлары һәм критерияләре (диагностика методы)

1. Бу әсәрне анализлаганнан соң, укучыларның белем дәрәҗәсен контроль эш яки контроль тест ярдәмендә тикшерү.
2. Уку елы азагында укучыларның тәрбиялелек дәрәҗәсен тикшерү.

Кулланылган әдәбият

1. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. — Казан: Мәгариф, 2007.
2. Заһидуллина, Д.Ф., Әдәби әсәргә анализ ясау/ Д.Ф. Заһидуллина, М.И.Ибраһимов. — Казан, Мәгариф, 2005.

3. Заһидуллина Д.Ф., Татар әдәбияты: Теория.Тарих/ Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов, Т.Ш. Гыйләҗев. — Казан: Мәгариф, 2004.
4. Заһидуллина Д.Ф., Яңа дулкында (1980–2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңалык) /Д.Ф. Заһидуллина. — Казан: Мәгариф, 2006.
5. Маликова Мәдинә. Югалган якутлар: Повестлар, пьесалар. — Казан: «Рухият» нәшрияты, 2004.
6. «Мәйдан» журналы, 2004, №7.
7. Ф. Хатипов «Әдәбият теориясе». — Казан: «Раннур» нәшр., 2000.
8. Хәзерге татар әдәбияты. — Казан: Мәгариф, 2008.
9. Яхин А.Г., Әдәбият дәресләре: Укытучылар, югары уку йортлары студентлары һәм укучылар өчен методик кулланма. — Казан: Мәгариф, 2003.

Сахабутдинова Анфиса Рифовна,
учитель русского языка и литературы
МБОУ «Сармановская гимназия»

ПРОЕКТНАЯ ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ В ПРОЦЕССЕ ПРЕПОДАВАНИЯ РУССКОГО ЯЗЫКА

В процессе обучения современный школьник должен получить не только предметные знания, но и умение применять эти знания в практической деятельности, поэтому методологической основой новых ФГОС является системно-деятельностный подход в обучении. Для того чтобы знания обучающихся были результатом их собственных поисков, необходимо организовать эти поиски, развивать познавательную деятельность учеников.

В процессе преподавания русского языка и литературы уделяю внимание развитию поисковой деятельности обучающихся. Проектная задача является именно такой формой организации учебного процесса, когда знания учащихся — результат их собственных поисков, подключения творческих способностей, умения регулировать самостоятельно процесс получения знаний и применения их на практике.

Проектная задача по форме и содержанию приближена к «реальной» ситуации и ориентирована на применение учащимися целого ряда действий, средств и приемов не в стандартной форме. Итогом решения такой задачи всегда является реальный продукт (текст, схема или макет прибора, результат анализа ситуации, представленный в виде таблиц, диаграмм, графиков,

рисунков), созданный детьми. Любая проектная задача преследует определенные педагогические цели: выявление у школьников способности к переносу известных способов действий в новую для них модельную ситуацию. Для достижения цели учащиеся должны продемонстрировать уровень сформированности умения учиться, взаимодействия в паре (группе), умения работать с разными источниками информации.

В зависимости от цели можно выделить следующие виды проектных задач:

– стартовые и итоговые предметные;
– тематические (обучающие);
– межпредметные и межвозрастные;
– контрольные предметные.

Например, проектная задача по русскому языку по теме «Эпистолярный жанр (письмо): особенности синтаксиса, пунктуации и лексики». Данная проектная задача является контрольной предметной, осуществляет межпредметную связь русского языка и изобразительного искусства.

Ребята работают в паре на индивидуальном листе. Продолжительность работы — 45 минут. Учащиеся распределяют между собой обязанности: редактор — составитель текста, художник-оформитель, отвечают на вопросы:

– Что такое письмо?
– Виды письма;
– Что такое открытка?
– Какие синтаксические отрезки обязательно должны быть использованы в тексте письма (открытки)?
– Какие слова должны быть использованы при составлении текста письма (открытки)?

– Создайте собственную открытку (новогоднюю поздравительную или праздничное приглашение);

– Оцените свою работу в парах.

Проектная деятельность — современная педагогическая технология, ориентированная не на интеграцию фактических знаний, а на их применение и приобретение новых знаний путем самообразования.

Обучение в пятом классе, по заинтересованности детей к обучению, является наиболее благоприятным для развития навыков проектной деятельности: им нравится самостоятельно обдумывать, обобщать, искать общие принципы и закономерности, а структура предмета «Литература» в 5 классе открывает возможности для обучения детей с использованием технологии проектов практически в любом разделе. Метод проектов позволяет эффективно формировать исследовательские навыки учеников, активизировать их деятельность, применять полученные знания.

В этом году мои обучающиеся 5 класса защитили проекты на тему «Волшебные слова», «Роль фразеологизмов в нашей речи», «Имена собственные в нашей речи», «Тайна моего имени», «Роль антонимов в пословицах», «Заимствованные слова в нашей речи».

